ГЛАВА ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Зирекле, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «20» мартыннан № 2

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авылы җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында
«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 октябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 30 октябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 октябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 30 октябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Зирекле авылы, Ленин урамы, 53 йорт адресы буенча урнашкан Зирекле клуб бинасында 2024 елның 31 мартына 10.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 октябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү

турында» 2023 елның 30 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыеннары карарларына чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу һәм аларны урнаштыру, скважина бораулау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәй көне территорияне чүп үләннәрдән чабу, ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, тирәлеген төзү ремонтлау (куакларны кисү, агач төпләрен казып алу, теяү һәм озатып җибәрү, агач аудару, агач сейрәп чыгу, агачны эшкәртү, ботакларны утильләштерү, бульдозер белән грунт эшкәртү, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК»».

3. Әлеге карарны «Интернет»: https://pravo.tatarstan.ru мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет»: https://novoseshminsk.tatarstan.ru/ мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга, Зирекле авылының Ленин урамы, 53 йорт, Ленин урамы, 68 йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында, Яңа Чишмә муниципаль районы порталында кабул ителгән көннән алып 10 эш көне дәвамында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән соң) үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы

Ж.Г. Гайфетдинов